КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 апрель г.Казань № 407

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә җитештерү эшчәнлеге һәм законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча техник совет турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә җитештерү эшчәнлеге һәм законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча техник совет турында» 2018 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 16 апрель, 302 нче; 2020 ел, 2 май, 359 нчы; 2023 ел, 9 февраль, 117 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә җитештерү эшчәнлеге һәм законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча техник совет турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына,» сүзләреннән соң «Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең норматив хокукый актларына»

сүзләрен өстәргә;

5 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенә» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин